# Бәйрәм белән сезне, хөрмәтле кооператорлар!

## ЯҢА ЮЛЛАР ЭЗЛӘП

Традиция буенча, кулланучылар кооперациясе өлкәсендә эшләүчеләр июльнең беренче шимбәсендә үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен - Кооператорлар көнен билгеләп үтәләр.

Кулланучылар кооперациясе заманында аз керемле сатып алучыларны беренчел ихтыяҗ товарлары белән тәэмин итү системасы буларак пайчылар средстволарына төзелгән булган һәм гомер - гомергә хезмәт күрсәтү базарында халыкның шушы категориясе мәнфәгатьләрен яклап килде. Кулланучылар кооперациясе үзенең шушы багъланышына асылда хәзер дә тугърылыклы, чөнки безнең төп сатып алучыларыбыз - авылда. Ә авыл кешесенең хезмәт хакы, һәм бу берәүгә дә сер түгел, чагыштырмача кечкенә, әле ул да вакытында бирелми, шуңа күрә халыкка товарларны исемлек буенча, алыначак хезмәт хакы хисабына бирү практикасы киң кулланылышта. Райпо сату итә торган товарларның төп ассортименты - үзебезнең республикада җитештерелгән товарлар һәм бу безгә бик иркенләп сайланып тору мөмкинлеген чикли. Райпо идарәсе товар бәяләренә мөмкин кадәр азрак өстәмә куярга тырыша, шуңа күрә, райпо төрле түләүләргә чумган булса да, ягулык, электр энергиясе, транспорт өчен түләүләр даими төстә артып торса да, авылда күпчелек товарлар - яшелчә, җиләк - җимеш, ярмалар, кайбер кондитер әйберләре базардагыдан арзанрак бәягә сатыла. Райпо, базар икътисадының барлык кыенлыкларын үз җилкәсендә көндәлек татыган хәлдә, аларны авырлык белән булса да җиңә барып, үз алдына куелган бурычларны хәл кылуның яңа юлларын эзләүне дәвам иттерә. Соңгы вакытта райпоның авыл һәм шәһәр җирендәге кибетләрен коллективларга арендага бирү буенча зур оештыру эше алып барыла. Шунысы бар, бу очракта кибетләрдә минималь куллану кәрҗиненә керә торган 19 товарның булуы мәҗбүри шарт итеп куела. Тагын шунысы әһәмиятле, арендаторларга кайбер төр салым һәм башка төр түләүләрдә билгеле бер өстенлекләр биреләчәк һәм, иң әһәмиятлесе, андый коллективлар мөстәкыйльлек плюс инициатива принцибы буенча эшләп үз карамакларындагы сәүдә нокталарының максималь файда китерүенә ирешү өчен тырышачаклар. Бүген бу юнәлештә уңай тәҗрибә бар да инде: Киекледә 3 кибет, универмагның бер бүлеге һәм ашханә арендага бирелде. Эшчәнлегебезнең нәтиҗәлелеген арттыруга ирешүнең икенче бер юлы - үз производствобызны киңәйтү һәм камилләштерү, чыгарыла торган товарларның сыйфатын яхшырту. Хәзерге вакытта алар райпоның товар әйләнешенең 24,1 процентын алып торалар. Өлгереп җиткән ихтыяҗдан чыгып, райпо Синдряков исемендәге хуҗалыкның трикотаж цехын үз балансына алды. Безнең киләчәккә планнарыбызда халыкка өс киемнәре тегү, көнкүреш техникасын ремонтлау кебек хезмәтләр күрсәтү нияте дә бар.

Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү эшен сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрү мөһим гамәли һәм социаль бурыч булып тора. Авыл товар җитештерүчесенә үз хуҗалыгыннан арткан итне һәм башка төр продукцияне урнаштыруда булышу - безнең бурыч шул. Бу уңайдан суган кабул итү сезоны хәзерләүчеләребез өчен аеруча киеренке булачак, чөнки якынча исәпләүләр буенча гына да быел суган 81,4 гектарда утыртылган һәм аннан 2000 тоннадан артык уңыш көтелә. Шулкадәр суганны үзвакытында сатып алырга да, отышлы урнаштырып халыкка вакытында акчасын да бирергә кирәк булачак.

Товарларның ассортиментын киңәйтү, хезмәт күрсәтүдә югары культурага ирешү, сәүдә нокталарының тышкы һәм эчке рәвешен үзгәртү - болар көннең өлгереп җиткән таләпләре. Һәм безнең күпчелек хезмәткәрләребез үзләренең көндәлек эшчәнлекләрендә шушы таләпләргә җавап бирәләр. Бүген без зур киеренкелек белән һәм бар көчләрен куеп эшләүче хезмәткәрләребездән кооппромторгтан сатучылар А.Никитина, Т.Черепанова, Елаур һәм Кизләү ваклап сату сәүдә предприятиеләреннән Н.Тимофеева, Г.Хәмәтҗанова, җәмәгать туклануы предприятиесе буфетчысы С.Җамалиева, азык - төлек комбинатының клиндер цехы эшчесе А.Идрисова, шоферлар Р.Кәлимуллин, А.Булатов һәм башкаларны олы хөрмәт белән телгә алабыз.

Кулланучылар кооперациясе системасы хезмәткәрләрен, күпсанлы пайчыларыбызны уртак һөнәри бәйрәмебез белән чын күңелдән котлап, һәммәсенә нык сәламәтлек, оптимистлык һәм киләчәккә ышаныч, гаиләләренә бөтенлек, мәшәкатьле хезмәтегездә уңышлар телим.

**М.МОРАТОВ,**
**район кулланучылар кооперациясе идарәсе рәисе.**

## Ресторан кунаклар ярата

***Җәмәгать туклануы предприятиесе райпода үзенчәлекле урынны тотадыр,мөгаен: промышленность товарлары, азык-төлек кибетләре белән чагыштырганда аның ашханәләре, бигрәк тә рестораны бервакытта да клиентларга кытлык кичерми. Быелның беренче яртыеллыгында алар тарафыннан 1 миллиард 170 миллионнан артык сумлык продукция реализацияләнгән, бу - планның үтәлеше 110 проценттан узып киткән дигән сүз. Күрсәткечләрнең куанычлы булуында, аерым алганда, «Колос» ресторанының да өлеше зур.Дөрес, план үтәлеше ул ресторан хезмәткәрләре эшчәнлегенең бер ягы гына, бүген коллектив клиентларны сыйфатлы, тәмле ризык белән тукландыруны иң беренче һәм мөһим бурыч итеп куя. Коллективка көн дә кызу:***



- Районкүләм бер чарада безнең катнашыбыздан башка үтми,- ди предприятиенең яшь, инициативалы директоры Илдар Яруллин. - Кызлар һәр килгән кунакларга югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтергә тырышалар.

Ике смена бишәр көн эшли, эш вакыты 11 әр сәгать каралган булса да, беркем исәпләшеп тормый,бу сәгатьләргә тагын бишәр өстәлгән очраклар күбрәк була. Шуңа да директор зур горурлык белән бер-бер артлы мактауга лаеклы кызларның исемнәрен атый.Аш пешерүчеләр Зөләйха Яруллина,Суфия Сөләйманова, Татьяна Молчанова, официантлар Рәмзия Казанцева, Наташа Феоктистова, Алсу Гыйльметдинова-алар һәркайсы тырыш, үз эшләрен төгәл үтәүче һөнәр ияләре.Ә бригадир - пешекче Лиля Викторовна Орешина әйдәүче, иң кирәкле урынга һәрчак үзвакытында килеп җитә.

Шулай да Фәридә Сафина хакында җитәкчелек аерым югары фикердә.«Бартовик» дип аталган хикмәтле һөнәр иясенә кайнар ашлар пешерү вазифасы йөкләнгән аңа. Фәридәнең җәмәгать туклануы предприятиесендә эшләвенә 10 елдан артык узып китте. Шул вакытта тәҗрибә дә туплады, коллективта хөрмәт тә казанды. «Тәмле куллы»-диләр аның хакында һәм күрәсең, аңа бу сыйфат тәҗрибә туплау дәверендә генә килмәгән, ә баштан ук ана каны белән салынган, чөнки тәмле пешерү ул үзе бер сәнгать: анда талант я бар, я юк... Шул уңай сыйфатларга өстәп, Фәридәнең татар хатыннарына хас түземлелегенә, барлык кыенлыкларны да зарланмыйча, аһ - ваһ итмичә күтәрә алуына, шундый көчле, нык холкы белән бергә физик яктан да зур көчкә ия булуына сокланып та, гаҗәпләнеп тә карыйлар биредә. Коллективы белән бергә Фәридә дә һөнәри бәйрәмен плитә артында тәмле-тәмле ашлар «конвейеры» янында каршы ала.

Ашларыгыз гел тәмле, йөзләрегез гел якты булсын сезнең!

**Рәсемдә: Фәридә Сафина.** **Н.КВАШНИНА фотосы.**



**«Сатып алучылар белән итәгатьле булуы, хезмәтенә намуслы карашы өчен Т.В.Черепановага рәхмәт белдерәсем килә». Т.Родионова».**

Шикәрчеләр поселогының азык-төлек кибетендә эленеп торган «Шикаятьләр һәм тәкъдимнәр» кенәгәсендәге бу юллар ялгыз түгел. Шул кибет хезмәткәрләренә бергә дә, аерым-аерым да рәхмәтләрен җиткерергә теләүчеләр, бәйрәмнәр белән котлаучылар байтак. Алар моңа лаеклы да, күрәсең.Тамара Черепановага килгәндә, ул биредә быел 20нче елын ваклап килә.Димәк шулкадәр гомере кеше арасында, халык белән аралашып яшәлгән. Ә клиентлар сизгер, холкындагы уңай һәм тискәре якларны бик тиз сизеп алалар.Сатучының аңа мөгамәләсе кайчак күпне хәл итә бит.Тамара күңелсезлекләрне йөзенә чыгармаска тырыша,сабыр холыклы. Инде 9 ел һәр эш көнендә Кормыш ягыннан килеп эшли,шуның өстенә нәни кызын да еракка, 1нче мәктәпкә укырга йөртә.

Ә коллектив аны грамоталы,эшен җиренә җиткереп башкара белүе өчен дә хөрмәтли. «Кайсы вакыт эшләргә уңаерак иде,- дип кызыксынабыз аңардан, - кибетләр тулы кеше булгандамы, әллә хәзер, кибетләрдә ешрак тынычлык хөкем сөргәндәме?» «Элек физик яктан кыенракка туры килсә дә, күңелне эчке канәгатьлек били иде. Хәзер киресенчә.Физик эш бермә - бер кимеде, әмма мораль яктан кыенрак шул»-ди ул. Әлбәттә, һәр эшнең үз кыенлыгы... Шулай эш кимеде дисә дә ул, кибет июнь аен әйбәт күрсәткечләр белән «япкан»: планны 115 процентка үтәгән.

**Рәсемдә: Тамара Черепанова һәм Аниса Яковлева сатып алучыларны якты йөз белән каршы алалар.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# Норлат сәхнәсендә

*Татар эстрадасының танылган йолдызлары Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов Норлат тамашачысына яхшы таныш инде - аларның һәр чыгышы тулы залларда уза. Бу юлы да аларның Норлатта, район мәдәният йортында узачак концерты аншлаг белән үтәсенә шикләнмибез. Шуңа күрә **8 июльдә, сишәмбе көнне** Зәйнәп белән Зөфәрнең һәм алар белән киләсе күпсанлы башка сәхнә осталарының концертын күреп калыйк дисәгез, билетларны алданрак алып куярга ашыгыгыз.*

***Концерт кичке сәгать 9нчы яртыда башлана.***



# ике йолдыз

## Котлыйбыз!

*Якты Күл авылында яшәүче кадерле кешеләребез - **әтиебез Минзакир һәм әниебез Гөлфизә Хисамовларның** бергә тормыш итүләренә 45 ел тула. Без аларны куанычлы бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез, шатлык, бәхет, сәламәтлек, тигез тыныч тормыш телибез.*

*Әти - әни, яшәгез сез*
*Авырлыклар белмичә.*
*Тормыш юлларыгыз үтсен*
*Кайгы - хәсрәт күрмичә.*
*Безнең күңел һәрчак сезгә*
*Телидер изге теләк.*
*Җир йөзендә*
*сездән башка*
*Берни юк кадерлерәк.*

***Балалары, кияүләре, киленнәре һәм оныклары исеменнән кызлары Гөлсинә.***



## Котлыйбыз!



Зирекле авылында яшәүче **әтиебез Шәйхулла Гарифулла улы һәм әниебез Гыйззелбәнат Гыйбадулла кызы Фәйзуллиннарга 70 яшь тула.**

Кадерле әтиебез һәм әниебез, сезне олы юбилеегыз белән котлыйбыз. **Сезгә тыныч озын гомер, сәламәтлек, шатлык теләп Шәфигулла, Тәнзилә, Илшат.**

60



Кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабабыз **Миншакир Хәбибулла улы Рәҗәповка** 80 яшь тула. Без аны чын күңелебездән котлыйбыз, озын гомер телибез.

Чәчләреңне, әткәй, чал басса да,
Күңелең иркен, һаман яшь әле.
Җаның тыныч, тәнең таза булсын,
Кайгы - хәсрәт күрми яшә әле.

**Тормыш иптәше, балалары, киленнәре, кияүләре, оныклары.**

## Белдерүләр

### Сатабыз

**Кәкре Атауда йорт.** Зәкиулла Садыйковка теләсә кайчан мөрәҗәгать итәргә.

***

**Электростанция ишегалдында төзелеп бетмәгән гараж.** Синдряков ур., 25 - 10 адресы, 5 - 14 - 18 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**ВАЗ - 2105.** Тел.: 2 - 17 - 38.

***

**1995 елгы «Москвич» (Каблук), кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 28 - 32.

***

**Бер бүлмәле фатир һәм «Алмалык»та бакча участогы.** Совет ур., 189 - 21 адресы буенча кичке 5тән соң мөрәҗәгать итәргә.

### Сатабыз яки алмаштырабыз

**Казанда Идел буенда (Обсерватория станциясе) кирпеч йорт (газы, суы, мунчасы, гаражы бар) сатыла яки алмаштырыла. Вариантлар да булырга мөмкин.** Тел.: 2 - 19 - 77 (иртәнге 9дан кичке 5кә кадәр).



### Белеп торыгыз

**Нефтьчеләр микрорайонындагы 2 нче номерлы мунча 21 июльдән капиталь ремонтка ябыла.**

МППның торак - коммуналь хуҗалыгы администрациясе.

***Дружба ур., 35 адресы буенча мөрәҗәгать итсәгез, сезгә фатир һәм автомобиль ачкычлары ясап бирәчәкләр. Якшәмбе һәм дүшәмбедән кала һәр көнне иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр эшлибез. Лицензиябез № 118711.***

1997 елда шәһәрнең 1 нче мәктәбеннән урта белем турында Рафаэль Рамил улы Язданов исеменә бирелгән А 3 № 0011115 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

Шәһәрнең 2 нче мәктәбеннән Ильнур Илсуар улы Сөләйманов исеменә бирелгән А № 0762579 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

1 нче мәктәптән Алина Вячеславовна Тайбулатова исеменә бирелгән АС № 0030916 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

***

Иске Чаллы урта мәктәбеннән Светлана Александровна Каткова исеменә бирелгән А № 1292225 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

## Бездә кунакта

# Равил Шәрәфиев:
# «ТОРМЫШТА МИН ҖИТДИ»

***Быелгы сабантуйда Норлатта булган кунаклар арасында Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты, М.Җәлил һәм Г.Тукай бүләкләре лауреаты Равил Шәрәфиев тә бар иде. Ул әледән - әле мәйдан түгәрәге уртасында халыкны эч катырып көлдерергә мәҗбүр итеп юморескалар сөйләве арасында безнең белән сөйләшеп алырга да өлгерде.***

- Норлатка мин беренче тапкыр 1959 нчы елда, Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесында укыганда Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова һәм башкалар белән бергә килгән идем. Компактлы эшчеләр поселогы, матур табигатьле авыллар, мул сулы Чирмешән буйлары истә калган.

Шуннан соң Норлатта кырык елга якын булмаганмын икән. Бу юлы килүемдә Норлатны танымадым диярлек: социаль, мәдәни үсеш дәрәҗәсен сөйләп - аңлатырлык түгел.

Халкы исә элеккегечә үк гади, аралашучан. Телевизордан еш күргәнгәдер инде, кайберләре мине гомер буе белгән кебек сөйләшәләр.

**- Сез сүз артыннан кесәгә керә торганнардан түгел инде... Аралашканда да һәммә халыкны сәхнәдәге кебек үк авызыгызга каратып тотасыз.**

- Мин үзем сәхнәдән юмор сөйләп кеше көлдерсәм дә, тормышта бөтенләй икенче төрле - җитдимен. Эш урыным - сәхнәдә үзгәрәм дә куям инде, валлаһи. Юмор әсәрләрен сайлауга да җитди якын киләм. З.Хәким хикәяләрен яратам. Г.Афзал шигырьләрен дә сәхнәдән еш сөйлим. Халык күңеленә хуш килсен, кешеләр бүгенге авыр заманда күңелләрен баскан авыр хисләрдән, җитмәүчәнлек, мәңге чишелмәс акча проблемасыннан азга гына булса да арынып торсыннар әле дим инде.

**- Равил абый, Сез бит үзегез драма театры артисты.**

- Әйе, Галиәсгар Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә чыгыш ясый башлавыма 36 ел тулды быел. Шушы чорда йөзләгән роль иҗат итәргә туры килде. Аларның берсе дә минем өчен икенчел әһәмияткә ия түгелләр.

**- Сезнең иҗат белән таныш булмаган кеше юктыр инде ул. Ә менә шундый танылган кешенең гаиләсе, балалары, ничек яшәүләре турында да беләселәре киләдер, мөгаен.**

- Үзем Балык Бистәсе районыннан мин. Хатыным Рушания белән 2 бала тәрбияләп үстердек. Ул эшләмәде, балалар тәрбияләү белән генә шөгыльләнде. Кызым Равия университет бетерде, хәзер аспирантурада укый. Ә яшь чагында үлеп китеп артист буласы килә иде.

Улым Вил университетның юридик факультетында читтән торып укый. Яшь чагында биергә оста иде, шуңа хореография училищесында укыды. Аягын имгәтмәсә, биюче булып китәсе иде. Сәнгатьнең бәясе кими барган бүгенге көндә мин аның үз юлымнан китмәвенә сөенәм дә әле хәтта. Ә хәзер республика милли - инвестиция банкында эшли Вил.

**- Норлаттан нинди хис - теләкләр белән китәсез?**

- Канәгатьләнү алып китәм мин биредән. Шатланам да - республика үзәгеннән ерак урнашкан һәм артистлар игътибарын еш «татымаган» бу төбәк халкы башкала артистларының чыгышын карап ничек сөенде бит. Бүгенге авыр заманда халык өчен мондый мөмкинлек тудырган район җитәкчелеге өчен дә сөендем: үз якташларын санлыйлар, якын күрәләр, шулай итеп сәнгатьне дә югары дәрәҗәгә куялар дигән сүз бу.

**Әңгәмәдәш - Р.ГИНЯЕВА.**

### Эшкә чакырабыз

**«Девон - Кредит» акционерлык банкының Норлат филиалы мәгълүматлар базалары белән эшләү өчен программалаучыны эшкә чакыра.** Тел.: 5 - 29 - 22.

***

**Күптармаклы җитештерү предприятиесенең (МПП) торак - коммуналь хуҗалыгы бер ел эчендә торак бирү шарты белән 4 нче һәм 5 нче разрядлы слесарьларны даими эшкә чакыра. Хезмәт хакы - айга 700 - 800 мең сум**. 2 - 10 - 97 телефоны буенча кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.

## Искә алыгыз

5 нче июльдә кызыбыз Гөлшат белән киявебез Рөстәм Сафиннарның фаҗигале төстә һәлак булуларына 2 ел тула. Аларны белүче һәркемнең мәрхүмнәрне искә алуларын, рухларына дога кылуларын сорыйбыз.

Әнисе, туганнары.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә. Заказ N 7209